МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 153/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«14» 11 2022

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 1 августындагы 82/о номерлы боерыгы белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 1 августындагы 82/о номерлы боерыгы белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлеккә (Э.Ю.Латыйповага) дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М. Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалык министрлыгының «_14_»
___11____2022 ел, №153/о
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 1 августындагы 82/о номерлы боерыгы белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.4 пунктының икенче абзацына «, мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша, шәхсән яисә Республика порталындагы шәхси кабинет аша тапшырылган» сүзләрен өстәргә;

3 бүлектә:

3.4 пунктының дүртенче абзацында «торак-коммуналь хуҗалык идарәсенең коммуналь хуҗалыгында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5.1.2 пунктның уникенче абзацын төшереп калдырырга;

3.7.1 пунктның беренче абзацында «торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга, «министр урынбасары тарафыннан» сүзләрен «министр урынбасарлары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.2 пунктның беренче абзацында «торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесенә» сүзләрен төшереп калдырырга, «министр урынбасарына» сүзләрен «министр урынбасарларына» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.3 пунктның беренче абзацында «торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга, «министр урынбасары» сүзләрен «министр урынбасарлары» сүзләренә алмаштырырга.

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Каты коммуналь калдыклар белән
эш итү өлкәсендә инвестиция
программаларын раслау һәм аларга
төзәтмә кертү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына (белешмәлек)
кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы хакимият органнары (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы

министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 231-14-02 | msagkh@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 231-15-86 | Rinatazg.Abdullin@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 231-14-04 | Ilnur.Nurmuhametov@tatar.ru |
| Инвестиция программалары бүлеге җитәкчесе | 231-14-06 | Roza.Muhametzanova@tatar.ru |
| Калдыклар белән эш итү бүлеге җитәкчесе | 231-14-32 | Diana.Voykova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге җитәкчесе | 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |

«.